| | |
|---|---|
| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЗАЙ-КАРАТАЙСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЗӘЙ-КАРАТАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2020 елның 12 февраленнән №3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2015 елның 20 ноябрендәге 22 номерлы «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының " Зәй-Каратай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм тәртипкә бердәм таләпләрне билгеләү максатларында Зәй-Каратай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 22 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

287 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«287. Җир асты коммуникацияләрендә аварияләр бетерелгәннән соң, юллар, тротуарлар өслекләрен торгызу эшләр тәмамланган мизгелдән соң, 287.1 каралган очраклардан тыш, 10 көнлек сроктан да соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 287.1 һәм 287.2 пунктлар өстәргә:

287.1. Җир эшләре тәмамланганнан соң, эшләр җитештерүче юл өслекләрен торгызу эшләрен башлап җибәрергә тиеш: урамнарның аркылы өзелгән урыннарында - тәүлек дәвамында;

машина юлының озынча өзелү урыннары - 5 көн эчендә;

җирле юлларны, тротуарларны, тулы кыйммәтле юлларны казу урыннары газоннар - 10 көннән дә соңга калмыйча.

Аны торгызу алдыннан асфальт өслекнең кырыйлары фреза белән эшкәртелергә тиеш.

287.2.Кышкы чорда, һава шартлары белән һәм температура режимы белән эшләү технологиясен үтәү уңайсыз булуга бәйле рәвештә, җир эшләре тәмамланмаган очракта, эш җитештерүче түбәндәгеләргә бурычлы: җир эшләрен җитештерү зонасында территорияне тәртипкә китерү буенча кирәкле чаралар үткәрергә;